# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 10

октябрь
1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 10*
*октябрь*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. заказы №004042 .
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

## Эчтәлек

### I

708.«Дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 6
709.«Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 18
710.«Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 26
711.«14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында белә торып ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 30
712.«Лицензияләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 30
713.«Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» *Татарстан Республикасы Законы* ........ 31
714.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 21 октябрендәге утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 33
715.Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен, рәис урынбасарларын раслау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 34
716.«Кама Аланы» Махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 37
717.«Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 38
718.«Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 39
719.«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 39
720.«Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 40
721.«Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 40
722.«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан

Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 41

723.«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 13 июлендәге Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 41

724.«Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 42

725.«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 43

726.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 21 октябрендәге утырышы көн тәртибенә өстәмә мәсьәлә кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 43

727.«Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе составындагы үзгәреш турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 44

**П**

728.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 45

729.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 45

730.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 46

731.«1999 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 46

732.«1999 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 48

733.«1999 елның IV кварталына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру гамәлләре турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 49

734.«1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................................ 50

735.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15

сентябрендәге XX пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............................ 50

III

736. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авыллардагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды Советы һәм ревизия комиссиясе составына үзгәртүләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .................................................................................................. 51

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 708. Дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында

### I БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1 статья. **Әлеге Закон белән җайга салына торган мөнәсәбәтләр**

1. Әлеге Закон белән дәүләт милкенә һәм җирле үзидарә милкенә хокукны гамәлгә ашырганда килеп чыга торган мөнәсәбәтләр җайга салына.

Дәүләт милкенә һәм җирле үзидарә милкенә хокукны гамәлгә ашырганда килеп чыга торган, әлеге Закон белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасының башка законнары һәм граждан законнары белән җайга салына.

2. Гражданнарның һәм юридик затларның милек хокукларын гамәлгә ашырганда килеп чыга торган мөнәсәбәтләр граждан законнары белән җайга салына.

3. Татарстан Республикасының башка законнарында булган һәм дәүләт милкенә һәм җирле үзидарә милкенә хокукны гамәлгә ашырганда килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокук нормалары әлеге Законга туры килергә тиеш.

2 статья. **Милек хокукының асылы**

1. Милекче үз мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү хокукына ия.

2. Милекче үз карамагындагы мөлкәткә карата законга һәм башка хокукый актларга каршы килми торган һәм башка затларның хокукларын, закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен бозмый торган теләсә нинди гамәлләрне үзе теләгәнчә башкарырга, шул исәптән үз мөлкәтен бөтенләйгә башка затлар милкенә бирергә, үзе милекче булып калып, аларга мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү хокукларын тапшырырга, мөлкәтне залогка салырга, аны башка ысуллар белән йөкләргә һәм аның белән бүтәнчә эш итәргә хокуклы.

3 статья. **Милек формалары**

1. Татарстан Республикасында хосусый милек, дәүләт милке, җирле үзидарә милке һәм милекнең башка рәвешләре таныла.

2. Барлык милекчеләрнең хокуклары тигез яклана.

**4 статья. Җиргә һәм башка табигый ресурсларга милекчелек**

1. Татарстан Республикасында җир кишәрлекләре хосусый милектә, дәүләт милкендә, җирле үзидарә милкендә һәм милекнең башка рәвешләрендә булырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы территориясе чикләре эчендәге җир асты байлыклары, су объектлары, урманнар, табигый шартларда үсүче үсемлекләр дөньясы объектлары һәм табигый шартларда ирektә йөрүче хайваннар дөньясы объектлары республика милке була.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән табигый ресурслар хөкүмәтара килешүләр нигезендә федераль милеккә тапшырылырга мөмкин.

## II БҮЛЕК. ДӘҮЛӘТ МИЛКЕ ХОКУКЫ

**5 статья. Дәүләт милке хокукы турында гомуми нигезләмәләр**

1. Россия Федерациясенең милек хокукында булган мөлкәте (федераль мөлкәт) һәм Татарстан Республикасының милек хокукында булган мөлкәте (Татарстан Республикасы мөлкәте) Татарстан Республикасында дәүләт милке була.

2. Татарстан Республикасы милке республика һәм коммуналь милектән тора.

Татарстан Республикасы милкендәге һәм аңа карата милекче хокуклары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика органнары тарафыннан башкарыла торган мөлкәт республика милке дип таныла.

Татарстан Республикасы милкендәге һәм аңа карата милекче хокуклары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары тарафыннан башкарыла торган мөлкәт коммуналь милек дип таныла.

Милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнары Татарстан Республикасы һәм тиешле район, республика буйсынуындагы шәһәр (алга таба — коммуналь төзелмә) исеменнән Татарстан Республикасы Конституциясендә, шушы Законда һәм әлеге органнарның статусын ачыклаучы актларда билгеләнә торган компетенцияләре чикләрендә хокуклар алалар һәм бурычлар үтиләр.

3. Әгәр законда бүтәнчә билгеләнмәгән булса, республика һәм коммуналь милектәге мөлкәт вакытлыча яки даими файдалану (биләү) өчен теләсә кайсы юридик яки физик затка тапшырылырга, Россия Федерациясенең, физик һәм юридик затларның һәм милек хокукына ия башка субъектларның мөлкәте белән берләштерелергә, залог предметы буларак файдалануга тапшырылырга, юридик яки физик затларга ышанычлы идарәгә тапшырылырга, тартып алынырга, бүтән

ысуллар белән файдаланылырга һәм аңа башка йөкләүләр тапшырылырга мөмкин.

4 . Федераль милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү федераль законнар, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе, милек мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 . Дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча республика органы һәм коммуналь мөлкәт белән идарә итүче җирле органнар тиешле республика һәм коммуналь милек объектларының реестрын алып баралар.

Күрсәтелгән реестрларны алып бару тәртибе һәм аларның эчтәлегенә бәйле таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6 с т а т ь я . **Республика милке хокукы**

1 . Республика милкендә түбәндәгеләр була:

– Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары, Татарстан Республикасының иминият, резерв һәм башка бюджеттан тыш фондлары акчалары;

– республиканың унитар предприятиеләре һәм учреждениеләре мөлкәте;

– дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика органнары мөлкәте;

– җир асты байлыклары, су объектлары, урманнар, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектлары.

2 . Республика милкендә түбәндәгеләр торырга мөмкин:

– җир кишәрлекләре;

– кыйммәтле кәгазьләр;

– хуҗалык җәмгыятьләрендәге (ширкәтләрендәге) өлешләр;

– республика мөлкәтен хосусыйлаштырганда төзелгән хуҗалык җәмгыятьләре балансында торган һәм аларның устав капиталларына кермәгән мөлкәт;

– республика күләмендә әһәмияткә ия тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр булган биналар, корылмалар һәм әйберләр;

– Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм бюджеттан тыш фондлары, республиканың унитар предприятиеләре һәм учреждениеләре акчалары исәбенә төзелгән яки сатып алынган башка мөлкәт, шулай ук законнар нигезендә башка сәбәпләрдә сатып алынган мөлкәт.

3 . Әгәр законда яки шартнамәдә бүтәнчә билгеләнмәгән булса, республика милкендәге мөлкәтне файдаланудан алынган әйберләр,

продукция, керемнәр республика милкенә керә.

4 . Республика милке Татарстан Республикасы чикләреннән тыш та булырга мөмкин.

5 . Татарстан Республикасы Дәүләт Советы милек мөнәсәбәтләрен җайга сала торган законнар кабул итә, аларга үзгәрешләр кертә, шулай ук республика милке мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Конституциясендә, әлеге Законда һәм башка законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра. Республика милкендәге мөлкәт белән идарә итүне һәм эш итүне Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, шулай ук Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары белән тиешле вәкаләтләр алган Татарстан Республикасының башка дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук гражданнар һәм юридик затлар гамәлгә ашыра.

7 статья. **Әйбергә хокук объекты һәм йөкләмәләр предметы буларак республика мөлкәте**

1 . Республика милкендәге мөлкәт хуҗалык алып бару хокукында – республика унитар предприятиеләренә яки оператив идарә итү хокукында республика учреждениеләренә беркетелә.

2 . Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары һәм республиканың унитар предприятиеләренә яки учреждениеләренә беркетелмәгән башка мөлкәте Татарстан Республикасы казнасын тәшкил итә.

3 . Хуҗалык алып бару һәм оператив идарә итү хокукында республиканың унитар предприятиеләренә һәм учреждениеләренә беркетелгән һәм закон нигезендә фәкать дәүләт милкендә торырга тиешле мөлкәттән кала, Татарстан Республикасы үзенең йөкләмәләре буенча республика милкендәге барлык мөлкәте белән җавап бирә. Дәүләт милкендәге җирне һәм башка табигый ресурсларны бурыч түләтү өчен алу законда каралган очракларда рөхсәт ителә.

8 статья. **Коммуналь милек хокукы**

1 . Коммуналь милек түбәндәгеләрдән тора:

– җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш фондлар акчалары;

– коммуналь унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр мөлкәте;

– дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары мөлкәте.

2 . Коммуналь милектә түбәндәгеләр торырга мөмкин:

– кыйммәтле кәгазьләр;

– хуҗалык җәмгыятьләрендәге (ширкәтләрендәге) өлешләр;

– коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштырганда төзелгән хуҗалык җәмгыятьләре балансындагы һәм аларның устав капиталына кермәгән

мөлкәт;

– җирле әһәмияткә ия тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр булган биналар, корылмалар һәм әйберләр;

– торак фонды;

– җирле бюджет һәм бюджеттан тыш фондлар акчалары, коммуналь унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр акчалары исәбеннән төзелгән яки сатып алынган башка мөлкәт, шулай ук әлеге Законның 9 статьясында каралган башка нигезләрдә сатып алынган мөлкәт.

3. Законда яки шартнамәдә бүтәнчә билгеләнмәгән булса, коммуналь милектәге мөлкәтне файдаланудан алынган әйберләр, продукция һәм керемнәр коммуналь милек була.

4. Коммуналь милек коммуналь төзелмә чикләреннән читтә дә булырга мөмкин.

5. Халык депутатларының җирле Советлары коммуналь милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен законнар нигезендә билгелиләр. Татарстан Республикасы законында бүтәнчә билгеләнмәгән булса, коммуналь милектәге мөлкәт белән җирле хакимиятләр мөстәкыйль идарә итәләр һәм эш итәләр.

6. Коммуналь милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү буенча республика буйсынуындагы шәһәрдәге район хакимияте вәкаләтләре Татарстан Республикасы законнары һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең тиешле дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары карарлары белән билгеләнә.

**9 статья. Коммуналь милек хокукы барлыкка килү нигезләре**

Коммуналь милек түбәндәгеләрдән формалаша:

1) җирле бюджетка, шулай ук бюджеттан тыш фондларга күчерелергә тиеш булган тупланган акчалардан алынырга тиешле салымнарны һәм башка түләүләрне алу юлы белән;

2) сату-алу, алмаштыру, бүләк итү яки граждан законнарында каралган башка төрле алыш-биреш итү хакындагы шартнамә нигезендә мөлкәт сатып алу юлы белән;

3) Татарстан Республикасы милкен республика милкенә һәм коммуналь милеккә бүлгәндә;

4) республика милкендәге объектларны шушы Законда һәм аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә коммуналь милеккә тапшырганда;

5) федераль милек объектларын федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә коммуналь милеккә тапшырганда;

6) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә коммуналь төзелмәләрне берләштергәндә, бүлгәндә яисә бетергәндә;

7) коммуналь милектәге мөлкәтне файдалану нәтиҗәсендә

продукция, әйберләр, керемнәр алу юлы белән;

8 ) граждан законнарында каралган башка нигезләрдә.

10 статья. **Әйбергә хокук объекты һәм йөкләмәләр предметы буларак коммуналь милек**

1. Коммуналь милектәге мөлкәт хуҗалык алып бару хокукы белән коммуналь унитар предприятиеләргә яки оператив идарә итү хокукы белән коммуналь учреждениеләргә беркетелә.

2. Җирле бюджет (район, шәһәр) акчалары һәм коммуналь унитар предприятиеләргә яки учреждениеләргә беркетелмәгән башка коммуналь мөлкәт коммуналь казнаны тәшкил итә.

3. Хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукы белән коммуналь унитар предприятиеләргә һәм учреждениеләргә беркетелгән мөлкәттән һәм закон нигезендә фәкать дәүләт милкендә генә булырга мөмкин мөлкәттән кала, коммуналь төзелмә үзенең йөкләмәләре буенча коммуналь милектә булган барлык мөлкәте белән җавап бирә.

11 статья. **Республика һәм коммуналь унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр**

1. Идарә итү, социаль-мәдәни яки коммерция характерында булмаган башка төрле вазыйфаларны гамәлгә ашыру өчен дәүләт идарәсенең вәкаләтле республика яки җирле органы тарафыннан төзелгән, тулысынча яки өлешчә Татарстан Республикасының республика бюджетыннан яисә җирле бюджетлардан финанслана торган коммерция белән шөгыльләнмәүче оешма республика учреждениесе яки коммуналь учреждение дип таныла.

2. Вәкаләтле республика органы яисә дәүләт идарәсенең җирле органы тарафыннан төзелгән һәм мөлкәт милекчесе тарафыннан үзенә беркетелгән мөлкәткә карата милекче тарафыннан хуҗалык итү хокукы бирелгән коммерция оешмасы республика яисә коммуналь унитар предприятие дип таныла.

3. Әлеге Законның 6 статьясындагы 5 нче өлешендә һәм 8 статьясындагы 5 нче өлешендә күрсәтелгән тиешле дәүләт идарәсе органнары республика предприятиеләре һәм коммуналь унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү хокукына ия.

4. Республика яки коммуналь унитар предприятиеләргә һәм учреждениеләргә мөлкәт Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән акт нигезендә беркетелә.

5. Хуҗалык алып бару хокукындагы мөлкәткә ия булган республика яки коммуналь предприятие, шулай ук мөлкәт үзенә оператив идарә итү өчен тапшырылган республика яисә коммуналь учреждение бу мөлкәтне граждан законнарында билгеләнгән кысаларда били, файдалана һәм аның белән эш итә.

**12 статья. Республика милкендә һәм коммуналь милектә булган мөлкәтне хосусыйлаштыру**

Республика милкендәге һәм коммуналь милектәге мөлкәт дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда гражданнар һәм юридик затлар милкенә тапшырылырга мөмкин.

## III БҮЛЕК. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ МИЛКЕНӘ ХОКУК

**13 статья. Җирле үзидарә милкенә хокук турында гомуми нигезләмәләр**

1. Милекчелек хокукы нигезендә шәһәрләр һәм авыллар, шулай ук җирле үзидарә гамәлдә булган башка төзелмәләр территорияләре карамагындагы мөлкәт җирле үзидарә милке була.

2. Җирле үзидарә милке гамәлдәге законнар белән тыелмаган теләсә нинди эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнү өчен файдаланылырга мөмкин. Законда бүтәнчә билгеләнмәгән булса, җирле үзидарә милке вакытлыча яки даими файдалану өчен теләсә кайсы юридик яки физик затка тапшырылырга, физик, юридик затларның мөлкәте һәм бүтән милек ияләре субъектларының мөлкәте белән берләштерелергә, залог предметы буларак файдалануга тапшырылырга, юридик яки физик затларга ышанычлы идарәгә тапшырылырга, тартып алынырга, башка ысуллар белән файдаланылырга мөмкин һәм аңа башка йөкләүләр тапшырылырга мөмкин.

**14 статья. Җирле үзидарә милкенә хокук**

1. Җирле үзидарә милкендә түбәндәгеләр була:

– җирле үзидарә бюджеты, җирле үзидарәнең бюджеттан тыш һәм валюта фондлары акчалары;

– җирле үзидарәнең унитар предприятиеләре һәм учреждениеләре, шул исәптән транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү, ремонт-төзелеш, торак-эксплуатация предприятиеләре мөлкәте;

– җирле үзидарә органнары мөлкәте.

2. Җирле үзидарә милкендә түбәндәгеләр булырга мөмкин:

– җир кишәрлекләре;

– торак фонды;

– җирле әһәмияткә ия тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр булып торучы биналар, корылмалар һәм әйберләр;

– кыйммәтле кәгазьләр;

– хуҗалык җәмгыятьләрендәге (ширкәтләрендәге) кертемнәр (өлешләр);

– фәкать дәүләт милкендә генә була торган мөлкәттән кала, башка мөлкәт.

Җирле үзидарә бюджеты һәм бюджеттан тыш фондлары акчалары исәбенә төзелгән яки сатып алынган мөлкәт җирле үзидарә милке була.

3 . Законда яки шартнамәдә бүтәнчә билгеләнмәгән булса, җирле үзидарә милкендәге мөлкәттән файдаланып алынган уңыш, продукция, керемнәр җирле үзидарә милке була.

4 . Җирле үзидарә милке аннан читтә дә булырга мөмкин.

5 . Җирле үзидарә исеменнән милекче хокукын җирле үзидарә органы һәм (яки) аның урындагы затлары гамәлгә ашыра.

6 . Җирле үзидарә милке белән идарә итү һәм эш итү буенча җирле үзидарә органнарының һәм (яки) урындагы затларының вәкаләтләре, җирле үзидарә милке белән идарә итү һәм эш итү, шул исәптән җирле үзидарәнең унитар предприятиеләрен һәм учреждениеләрен арендага тапшыру, төзү, аларны үзгәртеп кору һәм ябу тәртибе, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләренең устав капиталларына кертемнәр кертү тәртибе, мөлкәтне коммерция белән шөгыльләнмәгән оешмаларга тапшыру тәртибе Җирле үзидарә уставы, граждан законнары, җирле үзидарә органнарының әлеге Закон һәм башка законнар нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

15 статья. **Әйбергә хокук объекты һәм йөкләмәләр предметы буларак, җирле үзидарә мөлкәте**

1 . Җирле үзидарә милкендәге мөлкәт җирле үзидарәнең унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында яки җирле үзидарә учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелә.

2 . Җирле үзидарәнең бюджет акчалары һәм җирле үзидарәнең унитар предприятиеләргә яки учреждениеләргә беркетелмәгән бүтән мөлкәте җирле үзидарә казнасын тәшкил итә.

3 . Җирле үзидарә, үзенең йөкләмәләре буенча хуҗалык алып бару хокукы белән җирле үзидарәнең унитар предприятиеләренә яки оператив идарә итү хокукы белән җирле үзидарә учреждениеләренә беркетелгән мөлкәттән һәм законнар нигезендә фәкать җирле үзидарә милкендә генә була ала торган мөлкәттән кала, милек хокукындагы барлык мөлкәте белән җавап бирә.

16 статья. **Җирле үзидарә милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру**

Җирле үзидарә милкендәге мөлкәт Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге законнарда һәм җирле үзидарә органнарының үз компетенцияе чикләрендә кабул ителә торган карарларында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда гражданнар һәм юридик затлар милкенә тапшырылырга мөмкин.

## IV БҮЛЕК. ДӘҮЛӘТ МӨЛКӘТЕН ТАПШЫРУ

### 17 статья. Дәүләт мөлкәтен тапшыруга гомуми таләпләр

1. Республика милкендәге мөлкәт федераль, коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшырылырга мөмкин.

Коммуналь милектәге мөлкәт федераль, республика милкенә һәм җирле үзидарә милкенә тапшырылырга мөмкин.

2. Республика милкендәге мөлкәтне федераль милеккә тапшыру яклар тарафыннан билгеләнә торган килешү тәртибендә һәм шартларда Татарстан Республикасы Президенты яки Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла. Федераль милеккә тапшырыла алмый торган республика милкендәге мөлкәтләр исемлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

Коммуналь милектәге мөлкәтне республика милкенә тапшыру, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты белән килештереп, халык депутатларының җирле Советлары карары нигезендә җирле администрация тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Республика милкендәге мөлкәтне коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшыру турындагы карар дәүләт мөлкәте белән идарә итүче республика органы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы республика милке объектларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештереп коммуналь һәм җирле үзидарә милкенә тапшырыла торган төрләрен һәм исемлеген билгеләргә мөмкин.

4. Республика милкендәге мөлкәтне коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшыру, шулай ук коммуналь милектәге мөлкәтне җирле үзидарә милкенә тапшыру түләүсез гамәлгә ашырыла.

5. Республика милкендәге мөлкәтне коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшыру шушы Закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

Коммуналь милектәге мөлкәтне җирле үзидарә милкенә тапшыру, шушы Закон таләпләрен искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

### 18 статья. Коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшырылырга мөмкин булган республика милке объектлары

1. Коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тиешле территориядә урнашкан түбәндәге республика милке объектлары тапшырылырга мөмкин:

жир кишәрлекләре;

торак фонды һәм торак булмаган фондлар (торак булмаган биналар), шулай ук аларны эксплуатацияләүне тәэмин итүче инженерлык инфраструктурасы объектлары;

шартнамәләр нигезендә, шул исәптән аренда шартнамәләре нигезендә гражданнар һәм юридик затлар биләвендәге һәм (яки) файдалануындагы мөлкәт;

социаль-көнкүреш билгеләнешендәге республика унитар предприятиеләре, мөлкәти комплекслар буларак мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт учреждениеләре, шулай ук күрсәтелгән республика унитар предприятиеләренә һәм учреждениеләренә беркетелгән мөлкәтнең бер өлеше, аларның филиаллары, вәкилләре һәм структур бүлекчәләре, шул исәптән әлеге предприятиеләрне һәм учреждениеләрне үзгәртеп корганда, япканда һәм хосусыйлаштырганда да;

төзелеп бетмәгән объектлар;

законнар нигезендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына һәм җирле үзидарә органнары карамагына тапшырылган мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле бүтән мөлкәт.

2. Коммуналь милеккә тапшырыла торган республика милке объектлары составына – әлеге Законның 4 статьясы нигезендә фәкать республика милкендә генә була торган мөлкәт, җирле үзидарә милкенә тапшырыла торган объектлар составына фәкать дәүләт милкендә генә була торган мөлкәт кертелми.

**19 статья. Коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшырыла торган республика милке объектлары исемлеген билгеләү һәм килештерү тәртибе**

1. Республика милкендәге объектларны коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшыру җирле хакимият яки җирле үзидарә органы үтенече буенча гамәлгә ашырыла.

2. Җирле хакимият яки җирле үзидарә органы коммуналь милеккә яисә җирле үзидарә милкенә тапшырырга тәкъдим ителүче республика милкенең конкрет объектларын билгелиләр һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана торган рәвештәге исемлеккә кертәләр.

3. Җирле хакимият яки җирле үзидарә органы бу исемлекне республика дәүләт идарәсенең тармак органнары белән килештерә, ә республиканың унитар предприятиесенә яки учреждениесенә беркетелгән мөлкәтнең бер өлешен тапшырганда шулай ук әлеге предприятие, учреждение белән килештерә һәм килештерелгән исемлекләрне дәүләт мөлкәте белән идарә итүче республика органына җибәрә. Килештерелгән исемлекләр республика милке объектларын тапшыру турындагы үтенеч белән җирле хакимият яки җирле үзидарә

органы тарафыннан дәүләт мөлкәте белән идарә итүче республика органына җибәрелә. Мөлкәтне тапшыру турындагы мәсьәләне хәл итүгә кадәр килештерү өчен исемлекне баланс тотучыга җибәрү мизгеленнән һәм тапшыру турындагы мәсьәләне хәл иткәнче, исемлектә күрсәтелгән мөлкәтне теләсә нинди читләштерү тыела.

4 . Җирле хакимиятләр һәм җирле үзидарә органнары исемлекне республиканың унитар предприятиеләре һәм учреждениеләре һәм (яки) республика дәүләт идарәсенең тиешле тармак органнары белән килештергәндә мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән мөлкәтне тапшыруга ризалыгы яисә риза булмавы хакындагы язмача үтенсченә каршы җавап үтенеч алынган көннән соң бер ай вакыт эчендә үтенеч белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрелергә тиеш.

20 статья. **Республика милкендәге объектларны тапшыру яки тапшырудан баш тарту турында карар кабул итү**

1 . Дәүләт мөлкәте белән идарә итүче республика органы кергән исемлекне алган көннән соң бер ай вакыт эчендә аның шушы Закон таләпләренә туры килүен тикшерә һәм үзенең бәяләмәсе белән республика милке объектларын коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшыру турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына карар проекты кертә яисә исемлектә күрсәтелгән республика милке объектларын коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшырудан баш тарту хакында түбәндәге очракларда карар кабул итә:

объект теге яки бу коммуналь төзелмә яки җирле үзидарә чикләреннән читтә урнашканда;

объектны республика милкенә тапшыруга шушы Законда һәм бүтән законнарда каралган чикләүләр булганда;

республика унитар предприятиеләре яки учреждениеләре филиалларын, вәкиллекләрен, структур бүлекчәләрен оештыру һәм (яки) территориаль тәртиптә аерымлау мөмкинлеге булмавы тиешле республика дәүләт идарәсе тармак органының яки күрсәтелгән предприятие һәм учреждениенең язмача нигезләмәсе белән раслангканда;

республика унитар предприятиесе яки учреждениесе җитәкчесенең әлеге предприятиегә яки учреждениегә беркетелгән мөлкәтнең бер өлешен коммуналь милеккә яисә җирле үзидарә милкенә тапшыруга риза булмавы хакында язмача документ бирелгәндә.

Исемлеккә республика милкендә булмаган объектлар кертелгән очракта дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча республика органы исемлекне заявка бирүчегә кире кайтара.

Дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча республика органы исемлекне алган көннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына республика милкендәге объектларны

коммуналь милеккә яисә җирле үзидарә милкенә тапшыру турында карар проекты кертмәгән очракта, шулай ук исемлектә күрсәтелгән республика милке объектларын тапшырудан дәлилсез баш тартканда, җирле администрация яисә җирле үзидарә органы тапшырылучы объектлар исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына мөстәкыйль рәвештә җибәрергә хокуклы.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты исемлектә күрсәтелгән республика милкендәге объектларны коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшырудан баш тарту хакында түбәндәге очракларда карар кабул итәргә хокуклы:

республика дәүләт идарәсенең тиешле тармак органы республика милке объектларын коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшырудан баш тартуы хакында язмача нигезләмә биргәндә;

исемлектәге объект законнар нигезендә җирле дәүләт хакимияте һәм идарәсе органы һәм җирле үзидарә вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен файдаланыла алмаганда;

тиешле коммуналь төзелмәнең яки җирле үзидарәнең тапшырыла торган объектларны нәтиҗәле файдалану өчен финанс яки матди-техник мөмкинлекләре булмаганда.

3. Республика милке объектларын коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшыру турында карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тапшырыла торган объектларны карап тоту максатында Татарстан Республикасының республика бюджетыннан бүлеп бирелүче акча ресурсларын кабат бүлү хакындагы мәсьәләне карарга мөмкин, ә тиешле коммуналь төзелмәнең яки җирле үзидарәнең тапшырыла торган объектларның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен финанс яки матди-техник мөмкинлекләре булмаганда, акчалар мәҗбүри тәртиптә кабат бүленә.

4. Республика милкендәге объектларны тапшыру турында тәкъдимнәр җирле хакимияттән һәм җирле үзидарә органыннан бер үк вакытта кергән очракта, объектларны тапшыруда өстенлек җирле үзидарәгә бирелә.

21 статья. **Коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә милекчелек хокукы барлыкка килү**

1. Исемлектә күрсәтелгән республика милкендәге объектларны коммуналь милеккә яисә җирле үзидарә милкенә тапшыру яки тапшырудан баш тарту хакында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары әлеге исемлек дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча республика органына кергәннән соң ике ай эчендә кабул ителә.

Республика милкендәге объектларны коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшыру турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары коммуналь милекнең яки җирле үзидарә милкенең тапшырылган объектларга хокукын раслаучы документ була.

2. Әгәр карарда республика мөлкәтен тапшыруның вакыты

башкача билгеләнмәгән булса, республика милкендәге мөлкәтне коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә тапшыру Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карар кабул иткәннән соң бер айдан да соңга калмыйча тапшыру акты буенча гамәлгә ашырыла.

3 . Тапшырыла торган мөлкәткә коммуналь милек яки җирле үзидарә милке хокукы:

тапшыру актына кул куелган көннән;

законнар нигезендә мөлкәтне читләштерү факты дәүләт теркәве узарга тиеш булган очракларда, дәүләт теркәве узган көннән барлыкка килә.

4 . Дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча республика органы коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә тапшырылган объектларны коммуналь милеккә яки җирле үзидарә милкенә милекчелек хокукы барлыкка килгәннән соң бер атна вакыт эчендә республика милке реестрыннан төшереп калдыра.

## V БҮЛЕК. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

22 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе**

1 . Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге Законны кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында милек турында» Татарстан Республикасының 1991 елның 19 октябрендәге 1244-XII номерлы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, №3) көчен югалткан дип танырга.

3 . Үзләренең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштыруны Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итәргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2353

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

# 709. Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында

## I БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

**1 статья.** Республиканың бөтен территориясендә йә аның территориясенең бер өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә кертелүче гадәттән тыш хәл вакытлыча чара була һәм ул дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, юридик затларның хокукларын әлеге Закон нигезендә чикләүләрне, шулай ук аларга

өстәмә вазыйфалар йөкләүне билгеле алырлык эшчәнлегенең махсус хокукый режимын аңлата. Гадәттән тыш хәл фәкать гражданнарның иминлеген һәм Татарстан Республикасының конституциячел корылышын яклауны тәэмин итү мәнфәгатьләрендә генә кертелә ала.

**2 статья.** Гадәттән тыш хәл кертүнең максаты тиз арада хәлне тотрыкландырудан, законлылыкны һәм хокук тәртибен торгызудан, шулай ук һәлакәттән коткару һәм торгызуның кичектергесез эшләрен уздыру өчен шартлар тудырудан гыйбарәт.

## II БҮЛЕК. ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ КЕРТҮ ШАРТЛАРЫ, НИГЕЗЛӘРЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

**3 статья.** Гражданнарның иминлегенә яисә республиканың конституциячел корылышына гадәттән тыш чаралар кулланмыйча бетерүе мөмкин булмаган реаль куркыныч янаганда гына гадәттән тыш хәл кертелергә мөмкин.

**4 статья.** Әлеге Законның 3 статьясы таләпләре үтәлгәндә, гадәттән тыш хәл кертү өчен түбәндәгеләр нигез була ала:

а) конституциячел корылышны көч кулланып үзгәртергә тырышулар, көч кулланып башкарылучы массакүләм чуалышлар, гражданнарның гомеренә һәм иминлегенә яисә дәүләт институтларының нормаль эшчәнлегенә янаучы милләтара конфликтлар, аерым урыннарны блокадалау;

б) халыкның гомерен һәм сәламәтлеген куркыныч астына куючы һәм һәлакәттән коткару, торгызу эшләре үткәрүне таләп итүче табигый, техноген һәм биолого-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр.

**5 статья.** Татарстан Республикасының бөтен территориясендә яисә аның аерым урыннарында гадәттән тыш хәл Татарстан Республикасы Президенты Указы (алга таба Указ) белән кертелергә яисә озайтылырга мөмкин, кабул ителгән карар бер үк вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кертелә.

Республиканың бөтен территориясендә яисә аның бер өлешендә гадәттән тыш хәл кертү турында Татарстан Республикасы Президенты Указга кул куелган көндә Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

Россия Федерациясе Президенты республиканың бөтен территориясендә яисә аның бер өлешендә гадәттән тыш хәлне бары тик алдан Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының ризалыгын алгач кына кертә ала.

**6 статья.** Гадәттән тыш хәл кертү яисә аны озайту турындагы Указда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) әлеге Законның 3 һәм 4 статьялары таләпләре нигезендә га-

дәттән тыш хәл кертү яисә аны озайту өчен нигез булырлык шартлар;

б) әлеге Законның 3 статьясы таләпләре нигезендә гадәттән тыш хәл кертү яисә аны озайту зарурлыгын нигезләү;

в) әлеге Законның 17 һәм 18 статьялары таләпләрен үтәгән килеш, гадәттән тыш чараларның исемлеге һәм аларның чикләре, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, шулай ук юридик затларның хокукларын вакытлыча чикләүләрнең тулы исемлеге;

г) гадәттән тыш хәл режимын гамәлгә ашыру өчен җаваплы дәүләт идарәсе органнары һәм шушы органнарның гадәттән тыш вәкаләтләренең төгәл чикләре;

д) гадәттән тыш хәл кертелә яисә озайтыла торган территориянең чикләре;

е) Указның үз көченә керү вакыты, шулай ук гадәттән тыш хәл кертүнең яисә аны озайтуның төгәл вакыты.

Гадәттән тыш хәл кертү яисә аны озайту турындагы Указ, үз көченә кергәнче 6 сәгатьтән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чаралары аша халык игътибарына җиткерелә.

**7 статья.** Гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указ Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясе чорында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кичекмәстән тапшырылырга тиеш. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Указны 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча карый. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләре арасындагы чорда гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указ Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына тапшырылырга тиеш, ә ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш сессиясен кичекмәстән чакыру турында карар кабул итә, анда Дәүләт Советы гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указны ул кабул ителгәннән соң 72 сәгатьтән дә соңга калмыйча карый. Гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указ массакүләм мәгълүмат чаралары аша игълан ителгәндә, Татарстан Республикасы халык депутатлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышы булачак урынга махсус чакырусыз да мөмкин кадәр кыска вакытта килеп җитәргә тиеш.

**8 статья.** Әлеге Законның 7 статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланмаган гадәттән тыш хәл кертү яисә аны озайту турында Указ үз көчен югалта, бу хакта массакүләм мәгълүмат чаралары аша тиешле территория халкына җиткерелә.

**9 статья.** Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гадәттән тыш хәл 7 тәүлеккә кадәр кертелергә мөмкин, ә Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә гадәттән тыш хәлнең гамәлдә булу вакыты 60 көннән дә артык була алмый.

Татарстан Республикасы Президенты гадәттән тыш хәлнең гамәлдә булуын әлеге статьяның беренче өлешендә билгеләнгән

вакытка берничә мәртәбә озайтырга хокуклы. Гадәттән тыш хәлнең гамәлдә булу вакытын озайту турындагы указлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

Әгәр гадәттән тыш хәлне игълан итү өчен нигез булган хәлләр бетерелсә, Татарстан Республикасы Президенты гадәттән тыш хәлне гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указда билгеләнгән вакыт узганчы ук юкка чыгарырга хокуклы.

Гадәттән тыш хәлне гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указда билгеләнгән вакыт узганчы юкка чыгару яисә аны озайту турындагы карар кабул ителгән мизгеленнән үз көченә керә һәм кичекмәстән халыкка җиткерелә.

## III БҮЛЕК. ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ ЧОРЫНА КЕРТЕЛҮЧЕ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕ РӘВЕШЛӘРЕ

**10 статья.** Гадәттән тыш хәл кертелгән территориядә әлеге Закон нигезендә Указ белән идарәнең махсус рәвешләре кертелергә мөмкин.

Гадәттән тыш хәл шартларында идарә итүне гамәлгә ашыручы дәүләт органнарына хәлне тизрәк нормальләштерү, хокук тәртибен һәм законлылыкны торгызу, гражданнарның иминлегенә куркыныч янауны бетерү өчен кирәкле чаралар күрер өчен гадәттән тыш вәкаләтләр бирелергә мөмкин. Бу гадәттән тыш чараларда гражданнарның, әлеге Законның 18 статьясында санап кителгән хокукларыннан һәм ирекләреннән гайре, хокукларын һәм ирекләрен вакытлыча чикләү күздә тотылырга мөмкин.

**11 статья.** Гадәттән тыш хәл кертүне китереп чыгарган шартларны бетерү буенча эшләрне координацияләү өчен, шулай ук гадәттән тыш хәл кертелгән территориянең дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнары үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаган очракта, Указ белән вакытлыча махсус органнар оештырылырга мөмкин.

Махсус идарә итү рәвешләрен кертү, аларны юкка чыгару яисә аларның гамәлдә булу вакытын озайту турындагы карар, әгәр башкасы махсус килештерелмәгән булса, кабул итү мизгеленнән үз көченә керә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары аша кичекмәстән халыкка игълан ителә.

Вакытлы идарә органнарына гадәттән тыш хәл кертелгән территориядәге дәүләт идарәсе җирле органнарының башкарма һәм күрсәтмә бирү вәкаләтләре тулысынча яисә өлешчә тапшырылырга мөмкин.

Мондый органнарның гадәттән тыш хәл режимын тәэмин итү буенча боерыкларын һәм күрсәтмәләрен тиешле территориядә үтәү мәҗбүри.

**12 статья.** Гадәттән тыш хәл кертелгән территориядәге барлык дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр,

оешмалар, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар тиешле территориядә махсус идарә итү рәвешләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының вакытлы идарә органнары карарларын һәм күрсәтмәләрен үтәргә һәм аларга һәрьяклап ярдәм итәргә тиешләр. Карарларны һәм күрсәтмәләрне үтәмәү законнарда каралган җаваплылыкка китерә.

**13 статья.** Республиканың бөтен территориясендә яисә аның бер өлешендә идарә итүнең махсус рәвешләрен гамәлгә ашыручы вакытлы органнар түбәндәгеләргә хокуклы:

– әлеге Законның IV бүлегендә каралган чараларны күрергә;

– үз карамакларындагы территорияләрнең дәүләти, хуҗалык һәм социаль-мәдәни үсеше мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына керергә;

– дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары эшчәнлеген туктатып торырга, вакытлыча аларның вазыйфаларын башкарырга.

**14 статья.** Җәмәгать тәртибен тәэмин итү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген, иминлеген, хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау өчен эчке эшләр, дәүләт иминлеге органнарының, башка хокук саклау органнарының көчләре һәм чаралары кулланыла.

Халык байлыгына зыян килүне киметү максатында табигый, техноген һәм биолого-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча республика министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары җәлеп ителә.

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен махсус көчләр һәм чаралар билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителә.

## IV бүлек. Гадәттән тыш хәл шартларында күрелүче чаралар

**15 статья.** Гадәттән тыш хәл чорына түбәндәге чаралар билгеләнергә мөмкин:

а) гадәттән тыш хәл кертелгән территориягә керүнең һәм аннан чыгуның махсус режимы, шулай ук территория буйлап ирекле йөрүне чикләү;

б) җәмәгать тәртибен һәм халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүче объектларны, потенциаль куркыныч объектларны саклауны көчәйтү;

в) җыелышлар, митинглар уздыруны, урамда күмәкләшеп йөрүләрне, демонстрацияләрне һәм пикетларны, шулай ук массакүләм чаралар уздыруны тыю;

г) забастовкаларны тыю;

д) транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү һәм аларны тикшерү.

**16 статья.** Әлеге Законның 4 статьясындагы «а» пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча гадәттән тыш хәл кертелгән очракта, өстәмә рәвештә түбәндәге чаралар кертелергә мөмкин:

а) комендант сәгате, ягъни тәүлекнең билгеләнгән вакытында шәхесне раслаучы махсус бирелгән пропускларсыз һәм документларсыз урамнарда һәм башка җәмәгать урыннарында булуны тыю;

б) алдан цензура уздыру юлы белән матбугат һәм бүтән төрле массакүләм мәгълүмат чаралары иреген чикләү, гадәттән тыш хәл бетерелгәнгә кадәр матбугат продукциясенә вакытлыча арест салырга, шулай ук тавыш көчәйткеч техник чараларны һәм ишәйткеч аппаратураларны вакытлыча кулланудан алып торырга рөхсәт ителә;

в) сәяси фиркаләрнең, җәмәгать берләшмәләренең һәм массакүләм хәрәкәтләрнең хәлне яхшыртуны тоткарлый торган эшчәнлеген, тиешенчә кисәткәннән соң, туктатып тору;

г) гражданнар җыелып тора торган урыннарда документлар тикшерү, аерым очракларда, гражданнарда корал барлыгы турында мәгълүматлар булганда, аларның үзләрен, әйберләрен, торакларын һәм транспорт чараларын тикшерү;

д) корал, агулы матдәләр, спиртлы эчемлекләр сатуны чикләү яисә тыю, аерым очракларда гражданнардан – утлы һәм салкын коралны, сугыш кирәк-яракларын, агулы һәм шартлаткыч матдәләрне, ә предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан шулай ук өйрәнү хәрби техникасын һәм радиоактив матдәләрне дә вакытлыча алырга рөхсәт ителә;

е) әлеге урында яшәмәүче, җәмәгать тәртибен бозучыларны аларның даими яшәү урынына йә гадәттән тыш хәл кертелгән территориядән читкә үз исәпләренә чыгарып җибәрү.

Әлеге Законның 4 статьясындагы «б» пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча гадәттән тыш хәл керткән очракта, әлеге Законның 15 статьясында санап кителгән чараларга өстәмә итеп түбәндәге чаралар күрелергә мөмкин:

а) гражданнарны, аларга һичшиксез стационар яисә вакытлыча торак урыннары биреп, яшәү өчен куркыныч районнардан вакытлыча күчерү (эвакуацияләү);

б) азык-төлек продуктларын һәм беренчел кирәк-ярак предметларны бүлүнең махсус тәртибен кертү;

в) карантин билгеләү һәм бүтән санитария-эпидемиология чаралары күрү;

г) дәүләт предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары ресурсларын мобилизацияләү, аларның эш режимын үзгәртү, гадәттән тыш хәл шартларында кирәкле продукция җитештерүгә юнәлеш алу, һәлакәттән коткару һәм торгызу эшләрен башкару өчен кирәкле җитештерү эшчәнлегендәге башка үзгәрешләр;

д) гадәттән тыш хәл чорында үз вазыйфаларын җиренә җиткереп үтәмәгән дәүләт учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләрен эшләреннән читләштерү һәм әлеге җитәкчеләр урынына вазыйфаларны вакытлыча башкаручы башка затларны билгеләү;

е) ашыгыч рәвештә һәлакәттән коткару эшләрен башкару зарурлыгына бәйле аерым хәлләрдә әлеге эшләрне башкару өчен хезмәткә сәләтле халыкны һәм гражданнарның транспорт чараларын хезмәт иминлеген һичшиксез тәэмин итеп, мобилизацияләү рөхсәт ителә.

## V БҮЛЕК. ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ ШАРТЛАРЫНДА ГРАЖДАННАРНЫҢ ҺӘМ УРЫНДАГЫ ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ГАРАНТИЯСЕ ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

**17 статья.** Гадәттән тыш хәл шартларында кулланылучы һәм дәүләт органнарының законда билгеләнгән вәкаләтләрен, җәмәгать берләшмәләренең хокукларын, шулай ук гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм вазыйфаларын үзгәртүгә китерүче чаралар барлыкка килгән хәлнең кискенлеге таләп иткән кысаларда башкарылырга тиеш.

Республика территориясенең бер өлешендә мондый чараларны куллану гомум кабул ителгән халыкара хокук нормаларына каршы килмәскә тиеш һәм дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары вәкаләтләрен, җәмәгать берләшмәләре хокукларын, шулай ук башка урыннарда һәм тулаем республикада гражданнарның хокукларын һәм вазыйфаларын үзгәртүгә китерә алмый.

**18 статья.** Гадәттән тыш хәл кертү газаплаулар өчен, кеше абруен төшерә торган яисә аяусыз мөнәсәбәтләр яки җәзалар бирү өчен нигез булып хезмәт итә алмый. Гадәттән тыш хәл чорында гражданнарның Татарстан Республикасы Конституциясенең 25-27 статьяларында, 29 статьясындагы 1 өлешендә, 33 статьясындагы 2 өлешендә, 47 статьясында каралган хокуклары һәм ирекләре чикләнә алмый.

**19 статья.** Эчке эшләр органнарының, Дәүләт иминлеге комитетының, башка хокук саклау органнарының көчләрен, махсус чараларын һәм утлы коралларын куллану тәртибе һәм шартлары закон белән җайга салына һәм гадәттән тыш хәл шартларында үзгәртелергә тиеш түгел.

**20 статья.** Әлеге Законның 16 статьясы нигезендә билгеләнгән комендант сәгате кагыйдәләрен бозган гражданнар комендант сәгате беткәнчегә кадәр, ә үзләре белән документлары булмаган затлар шәхесләре ачыкланганчыга кадәр хокук тәртибен саклау көчләре тарафыннан, әмма өч тәүлектән дә артыкка түгел, тоткарланалар. Тоткарланган затлар һәм аларда булган әйберләр тентүгә дучар ителергә мөмкин.

Гадәттән тыш хәл игълан ителгән урыннарда гадәттән тыш хәл режимының билгеләнгән таләпләрен бозу, хокук тәртибен бозуга этәрүче гамәлләр, җәмәгать тәртибен саклау вазыйфаларын үтәгәндә милиция хезмәткәренең яисә башка затларның законлы күрсәтмәләренә яисә таләпләренә явызларча буйсынмау законнар нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

**21 статья.** Гадәттән тыш хәл режимын тәэмин итү өчен кабул ителгән актлар гадәттән тыш хәл туктатылуга ук, ул хакта махсус хәбәр ителмичә генә, үз көчен югалта.

Гадәттән тыш хәл бетерелгәч, гадәттән тыш хәл режимын бозулар турындагы эшләрне карау туктатыла, гадәттән тыш хәл режимын бозган өчен административ кулга алынган затлар кичекмәстән азат ителә.

**22 статья.** Гадәттән тыш хәлләр вакытында йә аларны туктату яисә бетерү буенча эш башкарылу аркасында зыян күргән гражданнарга тиешле дәүләт органнары, шулай ук предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан торак урыны бирелә, китерелгән матди зыян законнар нигезендә кире кайтарыла, эшкә урнаштыру буенча һәм кирәкле бүтән ярдәм күрсәтелә.

**23 статья.** Гражданнарның әлеге Законда билгеләнгән хокуклары гарантияләре бозылуны да кертеп, эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләрнең законсыз көч кулланулары, урындагы затларның хезмәт вәкаләтләрен арттырулары өчен законнар нигезендә җаваплылык билгеләнә.

**24 статья.** Гадәттән тыш хәл кертелгән территориядә хөкем итү бары тик судлар тарафыннан гына башкарыла.

Судларда суд эшләре гадәттән тыш хәл игълан ителгән вакытта гамәлдә булган Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә алып барыла. Суд эшләренең гадәттән тыш рәвешләрен кертү рөхсәт ителми.

## VI БҮЛЕК. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

**25 статья.** Гадәттән тыш хәл кертү турындагы Указны раслаган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы гадәттән тыш хәлнең бөтен чорында әлеге Законның үтәлешен тикшереп тора.

**26 статья.** Гадәттән тыш хәл гамәлдә булган чорда Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясен һәм сайлау турындагы законнарны үзгәртү рөхсәт ителми, референдумнар һәм сайлаулар үткәрелми.

**27 статья.** Гадәттән тыш хәл кертүгә китергән шартларның сәбәпләрен һәм аның нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле эшләрне финанслау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты

тарафыннан билгеләнә.

**28 статья.** Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2354

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 710. Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасының Законнар җыентыгын әзерләүнең һәм нәшер итүнең хокукый һәм оештыру нигезләрен билгели.

**1 статья.** Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы (алга таба – Законнар җыентыгы) – гамәлдәге законнарның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты норматив хокукый актларының системалаштырылган тулы рәсми җыентыгы.

Законнар җыентыгына түбәндәгеләр кертелә:

– Татарстан Республикасы Конституциясе;

– Татарстан Республикасы кодекслары;

– Татарстан Республикасы законнары;

– Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив характердагы карарлары;

– Татарстан Республикасы Президентының норматив характердагы указлары;

– Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының норматив характердагы карарлары;

– Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре.

Татарстан Республикасының Законнар җыентыгына норматив-хокукый актларның аерым нигезләмәләре (өземтәләре) кертелә ала.

**2 статья.** Законнар җыентыгы рәсми басмаларда нәшер ителгән законнардан һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан туплана.

**3 статья.** Татарстан Республикасының Законнар җыентыгына түбәндәгеләр кертелми:

– дәүләт, хезмәт, коммерция серен тәшкил итүче мәгълүматлары булган актлар;

– вакытлы характердагы актлар;

– элек билгеләнгән нормаларны үтәүне оештыруга юнәлдерелгән һәм яңа нормалары булмаган актлар, шулай ук оператив-күрсәтмә бирү

характерындагы башка актлар;

– бер генә тапкыр гамәлдә булган актлар (аларда булган инструкцияләрне, кагыйдәләрне һәм башка шуңа охшашлы актларны нәшер итү турындагы йөкләмәләрдән башка, әгәр әлеге актларны нәшер итү элек тиешле органнар компетенциясенә кермәсә);

– аерым предприятиеләргә, оешмаларга һәм учреждениеләргә кагылышлы, шулай ук гомуми әһәмияткә ия булмаган башка актлар;

– күмәртәләп һәм ваклап сату бәяләре дәрәҗәсен һәм хезмәт күрсәтү тарифларын, авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу бәяләре күләмен, хезмәткәрләрнең эш хакы күләмен җайга салучы актлар (хезмәт өчен түләүнең гарантияләнгән минималь күләмен билгеләүче актлардан башка);

– мәсьәләнең характеры аркасында хокукый җайга салу еш үзгәреп торучы башка актлар;

– элек нәшер ителгән актларның, әгәр алар Законнар җыентыгына кертелмәгән булса, үз көчләрен югалтуларын тану турындагы актлар.

**4 статья.** Законнар җыентыгын әзерләүне һәм нәшер итүне оештыру өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендә Законнар җыентыгын нәшер итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт комиссиясе төзелә (алга таба – Дәүләт комиссиясе). Дәүләт комиссиясе составына түбәндәгеләр керә: Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе һәм Татарстан Республикасы юстиция министры.

Дәүләт комиссиясе:

– Законнар җыентыгын әзерләүгә һәм яңартуга гомуми җитәкчелек итә;

– Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдиме буенча Законнар җыентыгының схемасын һәм аны туплауның төп принципларын раслый;

– әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны кертү яисә кертмәү (тулысынча яисә өлешчә) турында карар кабул итә;

– Законнар җыентыгына кертелмәгән законнарның һәм башка норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуларын тану турында, аларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына тәкъдимнәр кертә;

– аның томнарының һәм бүлекләренең эчтәлеген, Законнар җыентыгы проектына материаллар бирү тәртибен билгели;

– аны әзерләү буенча эш планын раслый;

– Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе

органнары, дәүләт фәнни һәм мәгариф учреждениеләре өчен Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын сайлап алу һәм эшкәртү, шулай ук Законнар җыентыгына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив– хокукый актларын эшләү буенча бурычлар билгели;

– тапшырылган томнарны һәм бүлекләрне карый һәм хуплый;

– Татарстан Республикасы законнарының алга таба үсешенә бәйле рәвештә Законнар җыентыгын яңарту тәртибен билгели.

**5 статья.** Законнар җыентыгын әзерләүгә һәм нәшер итүгә бәйле агымдагы эшләрне башкару өчен Дәүләт комиссиясе каршында, Законнар җыентыгының тиешле бүлеге үзенчәлеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы юстиция министры рәислегендә Татарстан Республикасының Законнар җыентыгын әзерләү һәм нәшер итү буенча эшче комиссияләр (алга таба – эшче комиссияләр) төзелә. Эшче комиссия составына министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарының җитәкчеләре, белгечләр, галим-юристлар һәм экспертлар кертелә.

Эшче комиссияләр:

– Законнар җыентыгына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны сайлап алу һәм эшкәртү буенча эшне координацияләүне гамәлгә ашыра;

– Законнар җыентыгы схемасы, аны туплау принциплары турында тәкъдимнәр әзерли;

– Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында, шулай ук Законнар җыентыгын әзерләүгә бәйле рәвештә аларның үз көчләрен югалтуларын тану турында тәкъдимнәр әзерли;

– Татарстан Республикасының Законнар җыентыгына кертелергә тиешле кодификацияләнгән норматив хокукый актлар проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында булган өзеклекләрне тулыландыру өчен кирәк булган башка актларны эшләү турында тәкъдимнәр әзерли;

– Законнар җыентыгын әзерләүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, фәнни учреждениеләр һәм оешмалар катнашуын күздә тоткан эш планнары проектларын эшли һәм Дәүләт комиссиясенә раслауга тапшыра, аларның үтәлешен тикшереп тора;

– Законнар җыентыгының әзерләнгән томнарын һәм бүлекләрен Дәүләт комиссиясенә карауга һәм хуплауга тапшыра.

– Эшче комиссияләрнең составлары һәм алар турындагы нигезләмә Дәүләт комиссиясе тарафыннан раслана.

**6 статья.** Законнар җыентыгы кәгазьдәге һәм машинадагы мәгълүмат тупламасы рәвешендә нәшер ителә. Басманың ике варианты да бертөрле юридик көчкә ия, шуның белән бергә машинада басылган

басмалар юридик көчкә законнарда билгеләнгән тәртиптә ия була.

Законнар җыентыгын тулаем яисә аның аерым томнарын һәм бүлекләрен нәшер итү һәм аларның тиражы турында карар Дәүләт комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

**7 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Законнар җыентыгын әзерләүдә һәм нәшер итүдә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары катнашуын тәэмин итә.

Законнар җыентыгын әзерләү һәм яңарту, аны кәгазьдә нәшер итү буенча турыдан-туры эшне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы башкара.

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив–хокукый актларны саклаганда аларның дөреслеген һәм бөтенлеген тәэмин итүне дә кертеп, Законнар җыентыгын әзерләүнең һәм аны нәшер итүнең программа-техник тәэмин ителешен, шулай ук аларны санкцияләштерелмәгән файдаланудан яклауны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы гамәлгә ашыра.

**8 статья.** Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуларын тану турындагы Татарстан Республикасы законнары проектлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив характердагы карарлары, шулай ук Законнар җыентыгына кертелергә тиешле әлеге норматив хокукый актларга аныклау характерындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлар проектлары закон чыгару инициативасының тиешле субъектлары тарафыннан кертелә һәм, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында беренче чиратта карала.

9 статья. Законнар җыентыгын әзерләү ике этапта башкарыла:

I этап – Татарстан Республикасының гамәлдәге, рәсми рәвештә гамәлдән чыгарылмаган барлык законнарын һәм башка норматив хокукый актларының, шул исәптән машина укырлык рәвештә дә, мәгълүматлар базасын формалаштыру (1999-2000 еллар);

II этап – Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарын һәм башка төрле норматив хокукый актларны системалаштыру, аларны Законнар җыентыгына кертү өчен әзерләү һәм билгеләнгән схемалар һәм принциплар нигезендә аның норматив корпусын формалаштыру (2000-2001 еллар).

**10 статья.** Законнар җыентыгын әзерләү һәм нәшер итү эшләрен финанслау Татарстан Республикасының республика бюджетында карала.

**11 статья.** Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2355

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 711. 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында белә торып ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында

Әлеге Закон 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның хокук бозуларын кисәтүгә юнәлдерелгән һәм ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның балаларны тәрбияләү вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен административ җаваплылыгын билгели.

**1 статья.** 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның терроризм акты турында белә торып ялган хәбәр иткәннәре өчен –

кисәтү ясала яисә ата-аналарына яки аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

Бер ел эчендә кабат шул ук гамәлләрне кылган өчен –

ата-аналарга яисә аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**2 статья.** Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан төзелә.

**3 статья.** Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр район (шәһәр) судлары тарафыннан административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта каралалар.

**4 статья.** Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен штраф суммалары административ материалларны карау урыны буенча шәһәрләрнең һәм районнарның бюджетларына җибәрелә.

**5 статья.** Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2371

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 712. «Лицензияләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

**1 статья.** «Лицензияләү турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советының Җыелма басмасы, 1999 ел, № 4) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Законның гамәлдә булуы этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше буенча эшчәнлекне лицензияләүгә, шулай ук лицензияләү үзенчәлекләре башка законнар белән билгеләнгән эшчәнлекнең бүтән төрләрен лицензияләүгә кагылмый».

**2 статья.** Әлеге Законны матбугатта басылган көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2372

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 713. Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында

Бу Закон латин графикасы нигезендә татар алфавитын тагын да камилләштерүгә һәм аның дөнья коммуникация системасына керүе өчен уңай шартлар булдыруга юнәлдерелгән.

**1 статья.**

Татарстан Республикасында, татар теленең үзенчәлекле авазларын чагылдыручы хәрефләрне исәпкә алып, латин графикасы нигезендә татар алфавиты торгызыла.

**2 статья.**

Татар алфавиты 34 хәрефтән раслана һәм түбәндәге тәртиптә һәм билгеләнештә урнаштырыла:

| | | | әйтелеше | |
|---|---|---|---|---|
| № | басма | язма | латиница | кириллица |
| 1 | A, a | A, a | a | а |
| 2 | Ə, ə | Ə, ə | ə | ә |
| 3 | B, b | B, b | be | бе |
| 4 | C, c | C, c | ce | җе |
| 5 | Ç, ç | Ç, ç | çe | че |
| 6 | D, d | D, d | de | де |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | E, e | *E, e* | e | е |
| 8 | F, f | *F, f* | ef | эф |
| 9 | G, g | *G, g* | ge | ге |
| 10 | Ğ, ğ | *Ğ, ğ* | ğı | гъ |
| 11 | H, h | *H, h* | he | һе |
| 12 | I, ı | *I, ı* | ı | ы |
| 13 | İ, i | *İ, i* | i | и |
| 14 | J, j | *J, j* | j | же |
| 15 | K, k | *K, k* | ke | ке |
| 16 | Q, q | *Q, q* | qa | къ |
| 17 | L, l | *L, l* | el | эл |
| 18 | M, m | *M, m* | em | эм |
| 19 | N, n | *N, n* | en | эн |
| 20 | Ŋ, ŋ | *Ŋ, ŋ* | eŋ | эң |
| 21 | O, o | *O, o* | o | о |
| 22 | Ө, ө | *Ө, ө* | ө | ө |
| 23 | P, p | *P, p* | pe | пе |
| 24 | R, r | *R, r* | er | эр |
| 25 | S, s | *S, s* | es | эс |
| 26 | Ş, ş | *Ş, ş* | şa | ша |
| 27 | T, t | *T, t* | te | те |
| 28 | U, u | *U, u* | u | у |
| 29 | Ü, ü | *Ü, ü* | ü | ү |
| 30 | V, v | *V, v* | ve | ве |
| 31 | W, w | *W, w* | wı | в (у) |
| 32 | X, x | *X, x* | xa | ха |
| 33 | Y, y | *Y, y* | y | й |
| 34 | Z, z | *Z, z* | ze | зе |

**3 статья.**

2011 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасында бер үк вакытта ике алфавит: латин графикасы нигезендәге һәм кириллица гамәлдә була.

**4 статья.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2001 елның 1 мартына кадәр Латин графикасы нигезендә татар алфавитын кертү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кертергә тиеш.

**5 статья.**

Әлеге Закон 2001 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2352

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 714. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 21 октябрендәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 21 октябрендәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен, рәис урынбасарларын раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. «Кама Аланы» Махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законын яңадан карау хакында.

3. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

4. «Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

5. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

6. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республика-

сы законы проекты хакында.

8. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

11. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 13 июлендәге Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

12. Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проекты турында.

13. «Җәмәгать тәртибен һәм идарә тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 18 маендагы 1858-XII нче карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

14. «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының жирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан үтәлүе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карарын үтәүнең барышы турында.

15. «Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртипкә салу гамәлләре турында» Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 нче карары хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2386

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 715. Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен, рәис урынбасарларын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карар бирә:

Судьялар итеп сайларга:

Казан шәһәренең Киров район судына

Шеверина Татьяна Михайловнаны;

Казан шәһәренең Мәскәү район судына

Агашина Наталья Васильевнаны һәм аны әлеге суд рәисе урынбасары итеп располарга;

Казан шәһәренең Идел буе район судына

Миңнәхмәтов Җәүдәт Җәүһәр улын һәм аны әлеге суд рәисе урынбасары итеп расларга;

Казан шәһәренең Совет район судына

Хәбирова Фәһимә Вәкил кызын;

Татарстан Республикасының Әгерже район судына

Вәлиев Әнис Мөхәммәт улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Азнакай шәһәр судына

Хәбибуллин Ренат Әхмәтҗан улын;

Татарстан Республикасының Алексеевск район судына

Гатина Наилә Миңнехан кызын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Әлмәт шәһәр судына:

Гафиятуллин Рафис Салих улын,

Исайчева Людмила Анатольевнаны,

Козихин Валерий Александровичны;

Татарстан Республикасының Апас район судына

Галәветдинова Фәридә Абзал кызын;

Татарстан Республикасының Арча район судына

Нуруллин Илгиз Миңнемулла улын,

Гыйниятуллин Рафыйк Каюм улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Бавлы шәһәр судына

Хәбипов Илкам Мәсвил улын;

Татарстан Республикасының Бөгелмә шәһәр судына:

Әхмәтов Эдвард Минһабетдин улын,

Летенков Валентин Георгиевичны,

Борисова Алевтина Юрьевнаны һәм аны әлеге суд рәисе урынбсары итеп расларга,

Федоров Василий Ивановичны һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Югары Ослан район судына

Бариев Рафаил Габделәхәт улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Алабуга шәһәр судына

Галиев Фәһим Гашыйк улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Зәй шәһәр судына

Нәфыйков Рифил Тимергали улын,

Дусаева Әлфия Малик кызын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Зеленодол шәһәр судына

Михалина Надежда Владимировнаны һәм аны әлеге суд рәисе урынбасары итеп расларга;

Татарстан Республикасының Кама Тамагы район судына

Гыйльмуллина Гөлчәчәк Фәрт кызын;

Татарстан Республикасының Кукмара район судына

Җаббаров Ринат Гандәлиф улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Лениногорск шәһәр судына:

Иваничев Владимир Васильевичны,

Шәйдуллин Эрик Алмаз улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәр судына:

Галиева Асия Мөхәммәтнур кызын,

Климин Юрий Александровичны,

Булатов Наил Нариман улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә район судына

Әхәтов Газинур Зөфәр улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Нурлат район судына

Галимова Фәридә Шәриф кызын;

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе район судына

Галиуллин Мансур Габдулла улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Питрәч район судына

Мусин Фәнис Сәхибетдин улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Тәтеш район судына

Хөснетдинов Дамир Гыйльман улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Тукай район судына:

Мансуров Әнвәр Фоат улын,

Пузырев Юрий Петровичны һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Чистай шәһәр судына:
Вафина Гөлсем Габдулла кызын,
Семенова Татьяна Михайловнаны һәм аны әлеге суд рәисе урынбасары итеп расларга;
Татарстан Республикасының Лениногорск шәһәр судына
Мурзин Наил Хөсәен улын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2387

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 716. «Кама Аланы» Махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Кама Аланы» Махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 1998 елның 25 ноябрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законын караудан төшереп калдыру хакында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдимен кире кагарга.

2. «Кама Аланы» Махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законы буенча түбәндәге составта килештерү комиссиясе төзергә:

| | | |
|---|---|---|
| Харисов Р.М. | - | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, комиссия рәисе |
| Галиев М.Һ. | - | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе рәисе |
| Когогин С.А. | - | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасының икътисад һәм сәнәгать министры |
| Кудрявцева А.Н. | - | Татарстан Республикасының икътисад һәм сәнәгать министрының беренче урынбасары |
| Хөсәенов Р.С. | - | Түбән Кама районының Кама Аланы эшчеләр поселогы администрациясе башлыгы |
| Паймухин В.Б. | - | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы бәйләнеш мәсьәләләре комиссиясе рәисе |

Әлеге килештерү комиссиясендә катнашу өчен түбәндәгеләрне чакырырга:

Хәмидуллин Ф.Г. - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы социаль-икътисадый мәсьә-ләләр буенча дәүләт киңәшчесе

Сәхиева Р.Г. - Татарстан Республикасы Президентының дәүләт-хокук идарәсе башлыгы

Яһудин Ш.Ш. - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы

3. Әлеге законны эшләп бетерү һәм аннан соң 1999 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясе каравына кертү өчен килештерү комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2388

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 717. «Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында

«Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» 1999 елның 16 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән редакциядә Татарстан Республикасы Президенты кире кайтарган Татарстан Республикасы Законын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Президентының искәрмәләрен исәпкә алып һәм редакция аныклаулары белән, кабат кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2389

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 718. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.
2. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дәрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2391

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 719. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турыында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.
2. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дәрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2392

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 720. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан **карар бирә:**

1. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2393

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 721. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2394

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 722. «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 21 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 21 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2395

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 723. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 13 июлендәге Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 13 июлендәге Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын, аңа тәкъдимнәр һәм искәрмәләр рәвешендә бирелгән төзәтмәләрне исәпкә алып, эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 21 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән тәкъдимрәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, 1999 елның 21 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2396

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 724. Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 21 ноябренә кадәр җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге кодекс проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 21 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре
1999 елның 21 октябре
№ 2397

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 725. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 16 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән редакциядә Татарстан Республикасы Президенты кире кайтарган Татарстан Республикасы Законын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Президентының искәрмәләрен исәпкә алып һәм редакция аныклаулары белән, кабат кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2398

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 726. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 21 октябрендәге утырышы көн тәртибенә өстәмә мәсьәлә кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 21 октябрендәге утырышы көн тәртибенә «Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе составындагы үзгәреш турында» өстәмә мәсьәләне кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2399

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 727. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе составындагы үзгәреш турында

«Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе Владимир Павлович Батуринны шәхси гаризасы нигезендә Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан азат итәргә.

2. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзасы итеп Казан дәүләт педагогия университеты студенты Алексей Александрович Серовны билгеләргә.

3. «Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча округ сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарында:

| | |
|---|---|
| «Батурин Владимир Павлович | Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе, Казан шәһәре» дигән сүзләр урынына: |
| «Серов Алексей Александрович | Казан дәүләт педагогия университеты студенты, Казан шәһәре» дигән сүзләрне язарга. |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәмmәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2400

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 728. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясен Казан шәһәрендә 1999 елның 17 ноябрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2373

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 729. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Президентының 2000 елга бюджет юлламасы турында.
2. «Мактаулы ана» Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
3. «Төсле металл ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм сату кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. «Тузган торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр һәм пикетлар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасы мировой судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

7. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «2000-2005 елларда йогышлы авыруларны вакцина белән профилактикалау» республика максатчыл программасы турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2374

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 730. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы көзге сессиясенең чираттагы утырышын 1999 елның 21 октябрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2375

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 731. 1999 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен, рәис урынбасарларын раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. «Кама Аланы» махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законын яңадан карау хакында.

3. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

4. «Экологик экспертиза турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

5. «Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

6. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

7. «Җирләрне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

9. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

10. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

11. «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 13 июлендәге Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проекты турында (I укылыш).

14. «Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советы карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

15. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатлары статусы турында» Татарстан Республикасы Законының Татарстан

Республикасы Прокуратурасы тарафыннан үтәлүе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карарын үтәүнең барышы турында.

16. «Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртипкә салу гамәлләре турында» Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 номерлы карары хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2376

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 732. 1999 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1 «Кама Аланы» махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законын яңадан карау хакында.

2. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3. «Экологик экспертиза турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

4. «Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

5. «Җирләрне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

6. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

7. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

8. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

9. «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

10. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 13 июлендәге Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

11. «Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында.

12. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының жирле Советлары халык депутатлары статусы турында» Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан үтәлүе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карарын үтәүнең барышы турында.

13. «Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртипкә салу гамәлләре турында» Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 номерлы карары хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2377

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӨҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 733. 1999 елның IV кварталына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру гамәлләре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның IV кварталына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру гамәлләре планын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2378

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 734. 1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мөрәҗәгатен исәпкә алып, «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертмәскә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2382

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 735. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге XX пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге XX пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Хәрби комиссариат адресына әйтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә.

Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында, бер айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 октябре
№ 2383

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

УКАЗ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 736. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авыллардагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды Советы һәм ревизия комиссиясе составына үзгәртүләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авыллардагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды эшчәнлеген камилләштерү, аның карамагына җибәрелгән средстволарның тотылышына контрольне тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Президентының 1995 елның 6 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авылдагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды турында»гы 614 нче Указының (Татарстан Республикасы Президентының 1996 елның 10 июлендәге 419 нчы, 1996 елның 24 июлендәге 444 нче, 1998 елның 22 декабрендәге 1056 нчы указлары белән кертелгән үзгәртүләрне исәпкә алып) икенче пунктын үзгәртеп, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авылдагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды советының түбәндәге составын расларга:

**Совет рәисе**

| | |
|---|---|
| **Швецов Владимир Александрович** | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |

**Совет рәисе урынбасарлары:**

| | |
|---|---|
| **Миңнеәхмәтов Җәүдәт Мидхәт улы** | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авыллардагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды башкарма директоры |
| **Шәйдуллин Илдус Барый улы** | Татарстан Республикасы төзелеш һәм коммуналь хуҗалык министры |

**Совет әгъзалары**

| | |
|---|---|
| **Васильев Валерий Павлович** | Татарстан Республикасы Дәүләт милкен идарә итү дәүләт комитеты рәисе |
| **Кантюков Рәфкать Абдулхәй улы** | җаваплылыгы чикләнгән «Таттранс газ» җәмгыятенең генераль директоры |
| **Ханбиков Ринат Сәгыйть улы** | «Татгазинвест» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры |
| **Петров Борис Германович** | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының максатчан бюджет фондларына идарә итү департаменты директоры |
| **Владимиров Николай Михайлович** | Татарстан Республикасы Минзәлә районы хакимият башлыгы |
| **Идиатуллин Фарук Ислам улы** | Татарстан Республикасы Мамадыш районы хакимият башлыгы |

2. Татарстан Республикасы Президентының 1995 елның 6 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авылдагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды турында»гы 614 нче Указның (Татарстан Республикасы Президентының 1996 елның 10 июлендәге 419 нчы, 24 июлендәге 444 нче, 1998 елның 22 декабрендәге 1056 нчы указлары белән кертелгән үзгәртүләрне исәпкә алып) өченче пунктын үзгәртеп, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы районнарга, шәһәрләргә, авыллардагы торак пунктларына газ кертү буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды ревизия комиссиясенең түбәндәге составын расларга:

| | |
|---|---|
| **Чернов Павел Петрович** | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының максатчан бюджет фондларына идарә итү департаменты директоры урынбасары |
| **Кәримов Шаһит Мөкәрәм улы** | җаваплылыгы чикләнгән «Таттрансгаз» җәмгыяте баш бухгалтеры |
| **Сухоруков Сергей Иванович** | Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар буенча министрлыгы идарәсенең Татарстан Республикасындагы бүлеге башлыгы |

3. Указ кул куйган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль,
1999 ел, 18 октябрь
№ УП-798